ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

05. 08. 2017 г. Казань № 072-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы белән расланган Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәнең 16 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибен расларга.
2. Хокукый һәм кадрлар эше бүлеге түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

әлеге боерык белән Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук алар белән котрактлар төзегәндә гражданнарны таныштыруны;

Тәртипне Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының мәгълүмат стендында урнаштыруны.

3. Архив тармагын мәгълүматлаштыру секторы әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 05.06.2017 № 072-од боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибе**

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибе (алга таба – Тәртип) хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә түбәндәгеләрнең керү процедурасын регламентлый:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары турында Рәис боерыгы белән расланган исемлегенә кертелгән граждан мөрәҗәгате, коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирү турында мөрәҗәгате, әгәр шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел узганчы;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында белешмәләрне бирергә мөмкинлеге булмау хакындагы гаризасы;

территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларына ия булган дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнар тарафыннан кулга алынган яисә аның ихтыярына яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган баларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән сәбәпләр буенча счетлардан (кертемнәрдән), акчаларыннан һәм кыйммәтле нәрсәләреннән һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларыннан файдалану һәм аларга ия булу тыелуга бәйле рәвештә «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы

Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау хакында дәүләт хезмәткәренең гаризасы.

Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерерлек яисә мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булырлык шәхси кызыксынуы турында хәбәрнамәсенең Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына керү һәм аны карау тәртибе «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 №119-од боерыгы белән җайга салына.

2. Граждан мөрәҗәгате һәм дәүләт граждан хезмәткәре гаризасы әлеге Тәртипкә 1, 2, 3 нче кушымталар нигезендә язма рәвештә төзелә һәм эшләр алып бару һәм оештыру эше секторы аша Рәисә җибәрелә.

3. Рәис (аның вазыйфасын башкаручы зат) өч эш көне эчендә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) мөрәҗәгатьне (гаризаны) җибәрә.

4. Комиссия мөрәҗәгатьне (гаризаны), аңлатуны һәм башка материалларны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 18.01.2017 № 006-од боерыгы белән расланган нигезләмә нигезендә карый.

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибенә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисенә
____________________________________
____________________________________
(вазыйфасы атамасы) (Ф.Ис.Ат. ис., телефон номеры)

Объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында белешмәләрне бирергә мөмкинлеге булмау хакындагы

## ГАРИЗА

Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында белешмәләрне бирергә мөмкинлеге булмау хакында хәбәр итәм ______________________________________________________________

(хатынымның (иремнең) һәм балигъ булмаган балаларымның Ф.Ис.Ат. ис., туган датасы)

______________________________________________________________

сәбәпләре ____________________________________________________
(Комиссия ташырылмаган белешмәләр турында объектив һәм ихтирамга лаек характерда нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм хәлләр күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны кушып бирәм (булган очракта): ____________________________________________________
(өстәмә материаллар күрсәтелә)

Әлеге белешмәләрне тапшыру өчен граждан хезмәткәре күргән чаралар:____________________________________________________

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында әлеге гаризаны караганда шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәгенең астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| __________ | __________ | ______________________ |
| (датасы) | (имзасы) | (имзсы расшифровкасы) |

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибенә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисенә

______________________________

______________________________

(вазыйфасы атамасы) (Ф.Ис.Ат. ис., телефон номеры)

Гариза

Территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларына ия булган дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнар тарафыннан кулга алынган яисә аның ихтыярына яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган баларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән сәбәпләр буенча счетлардан (кертемнәрдән), акчаларыннан һәм кыйммәтле нәрсәләреннән һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларыннан файдалану һәм аларга ия булу тыелуга бәйле рәвештә «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү буенча мөмкинлегем юклыгы турында хәбәр итәм.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(Комиссия ташырылмаган белешмәләр турында объектив һәм ихтирамга лаек характерда нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм хәлләр күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны кушып бирәм (булган очракта): ______________________________________________________________________

(өстәмә материаллар күрсәтелә)

Күрелгән чаралар:

---

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында әлеге гаризаны караганда шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәгенең астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| ___________ (датасы) | ___________ (имзасы) | ________________________ (имзасы расшифровкасы) |

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибенә

3 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисенә

____________________________________

____________________________________

(вазыйфасы атамасы) (Ф.Ис.Ат. ис., телефон номеры)

Коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә)
ризалык бирү турында
мөрәҗәгать

Мин,____________________________________________________________

(Ф.Ис. Ат. Ис.)

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында _____ алып ______ кадәр чорда дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы биләүче ______________________________________________________________________

(вазыйфа атамасы)

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә түбәндәге вазыйфаны биләүгә ризалык бирүегезне үтенәм______________________________________
__________________________________________________________

(граждан биләргә җыенучы вазыйфа атамасы)

______________________________________________________________да

(коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешма атамасы)
йә граждан-хокукый шартнамә нигезендә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә)
(граждан башкарырга җыенучы эшләр, хезмәт күрсәтүләр төрләре)

______________________________________________________________да

(коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешма атамасы)

Минем вазыйфаи бурычларыма түбәндәгеләр керәчәк (мин башкарачак эшләргә түбәндәгеләр
керәчәк):___________________________________________________________

(граждан-хокукый шартнамә төзелгән очракта, вазыйфаи бурычларның, башкарылачак эшләрнең кыскача тасвирламасы)

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында әлеге гаризаны караганда шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәгенең астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| __________ | __________ | ______________________ |
| (датасы) | (имзасы) | (имзасы расшифровкасы) |